ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

| | | |
|---|---|---|
| **РАСПОРЯЖЕНИЕ** | Зеленодольск | **БОЕРЫК** |
| **11.03.2016** | шәһәре | **№ 245** |

Зеленодольск шәһәре территориясен санитар чистарту һәм төзекләндерү буенча гомумшәһәр чараларын үткәрү турында

«Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен санитар чистарту һәм аны халыкның санитар – эпидемиологик һәм экологик иминлегенә туры килә торган халәткә җавап бирү максатларында,

1. 2016 елның 30 мартыннан 2016 елның 31 маена кадәр Зеленодольск шәһәре территориясен санитар чистарту һәм төзекләндерү буенча икеайлык (алга таба – икеайлык) игълан итәргә.

2. Шәһәр территориясен санитар чистарту буенча 2016 елның 30 мартында, 2016 елның 06 апрелендә, 2016 елның 13 апрелендә, 2016 елның 20 апрелендә, 2016 елның 27 апрелендә, 2016 елның 04 маенда, 2016 елның 11 маенда, 2016 елның 18 маенда, 2016 елның 25 маенда чәршәмбе өмәләрен җыештырулар үткәрергә.

2016 елның 02 апрелендә, 2016 елның 09 апрелендә, 2016 елның 16 апрелендә, 2016 елның 23 апрелендә, 2016 елның 30 апрелендә, 2016 елның 07 маенда, 2016 елның 14 маенда, 2016 елның 21 маенда, 2016 елның 28 маенда халык катнашында йорт яны территорияләрен җыештыру буенча идарәче компанияләргә, торак милекчеләре ширкәтләренә, күчемсез милекчеләр ширкәтләренә шимбә өмәләрен оештырырга.

3. Оештыру-хокукый формаларына һәм милек рәвешләренә карамастан, предприятие, оешма, учреждение җитәкчеләренә, территориаль иҗтимагый үзидарәләр, бакчачылык җәмгыятьләре һәм гараж кооперативлары рәисләренә шәһәр территорияләренең беркетелгән кишәрлекләрендә санкцияләнмәгән чүплекләрне санитар чистарту һәм бетерү буенча чәршәмбе өмәләрен оештыруны тәкъдим итәргә.

Икеайлыкны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы затларны үз боерыклары (күрсәтмәләре) белән билгеләргә. Боерыкларның (күрсәтмәләрнең) күчермәләрен 2016 елның 25 мартына кадәр 4-64-43 факсы буенча «Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалыгы департаменты» МБУнә яки электрон почтага blag3@mail.ru тапшырырга.

Чәршәмбе, шимбә өмәләрендә катнашкан кешеләр саны, техника турында мәгълүматны атна саен 4-62-33 телефоны аша хәбәр итәргә.

Фотофиксацияне атна саен blag3@mail.ru электрон почтасына җибәрергә.

Техникага заказны 3-11-21 телефоны буенча («Коммуналь хуҗалык» МУП диспетчерлык хезмәте) башкарырга.

4. "ТР торак-коммуналь хуҗалыгы департаменты" МБУна тәэмин итәргә:

- икеайлыкны үткәрү буенча эшләрне координацияләү һәм оператив мәгълүматлар җыярга;

- подрядчы махсуслаштырылган оешмаларга 2016 елның 30 мартына кадәр шәһәр территорияләрен механикалаштырылган җыештыру өчен техника әзерләүне үткәрергә.

5. Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрлыгының үзәк территориаль идарәсе Зеленодольск бүлегенә, санитар – экологик иминлекне тәэмин итү өчен, Зеленодольск шәһәре территориясендә сәнәгать һәм көнкүреш калдыклары белән эш итүне җайга салу өлкәсендә контрольне көчәйтергә тәкъдим итәргә.

6. «Коммуналь хуҗалык» МУП чәршәмбе, шимбә өмәләре үткәрү урыннарында җыелган чүп-чарны үзәкләштерелгән рәвештә чыгаруны тәэмин итәргә.

«Экоресурс» МУП каты көнкүреш калдыклары полигонына чүп-чар кабул итүне тәэмин итәргә.

7. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалык департаменты» МБУ җитәкчесе О.В. Анисимовка йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Сәхибуллин